СОҢГЫ БУРЫЧ

Казанда ефрейтор Дамир Гыйлемхановны соңгы юлга озаттылар

> 2

ТӨЗЕЛЕШ СЕЗОНЫ

Атна-ун көннән республикада кызу төзелеш сезоны башланачак

> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ

Татарстан Президенты имзалаган яңа закон

> 3

«ТАТНЕФТЬ»ТӘН – ТАЛАНТЛАРГА

Татарстанның нефть төбәгендә күренекле музыкантлар махсус мастер-класслар уздыра

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 54 (28827) | Шимбә | 16 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

ИГЕНЧЕЛӘР ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕНӘ КЕРЕШТЕ

Игенчеләр өчен иң җаваплы чор башланды. Уңай һава торышына һәм ашлама, орлык, запас частьлар белән тоткарлыксыз тәэмин ителешкә өмет итеп, алар язгы кыр эшләренә чыкты.

Шушы берничә көндә Азнакай, Зәй, Бөгелмә, Буа, Сарман, Лениногорск, Аксубай, Ютазы, Әлки, Спас һәм Алексеевск районнары аграрийлары күпьеллык үләннәрне тукландыруга кереште. Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдим иткән мәгълүматлар буенча, быел чәчү мәйданнары үзгәрешсез кала. Алар 2,72 млн гектарны тәшкил итә. Шулардан бөртекле һәм кузаклы культуралар – 1,6 млн, техник культуралар – 375 мең, терлек азыгы 761 меңне тәшкил итәчәк. Бәрәңге һәм яшелчәгә дә зур игътибар бирергә ниятлиләр. Аларның мәйданнарын 10 процентка арттырып, 6,6 мең гектарга җиткерү планы бар.

Быел җирдә дым да җитәрлек булды. Россельхозцентрның Татарстан буенча филиалы белгечләре әйтүенчә, әлеге вакытка нибары өч районда – Әгерҗе, Биектау, Лаешта гына кырлар тулысынча кар астында. Аеруча Лаеш районының «Волжская» җәмгыяте кырларында кар күп икән: 40 см.

– Чистай районындагы кырларда кар эреп беткән диярлек, Баулы кырлары тулысынча ачылган, – ди оешма җитәкчесе урынбасары Любовь Занина. – Республикада кар тиз эреде. Апрельнең беренче декадасы 1–3 градуска җылырак булды. Гадәттә 10 апрельгә республика территориясенең өчтән ике өлешендә 20–30 см кар ята торган иде. Быел Кама аръягы районнарында кырлар кардан тиз арада чистарды. Бу уҗымнар өчен аеруча яхшы.

«ВТ» архивыннан

Орлыклар кайтып бетте

Билгеле булганча, быелга республикада бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар өчен күңел тыныч: алар белән тәэмин ителеш 15 процентны тәшкил итә. Ә менә шикәр чөгендере, көнбагыш һәм кукуруз белән кыенлыклар барлыгы турында гел әйтә киленде. Аерым алганда, хуҗалыклар март аенда кукуруз белән – 92, шикәр чөгендере – 77, көнбагыш белән 75 процент кына тәэмин ителгән иде. Бүген вазгыять ни хәлдә соң?

– Быелга борчылырлык урын юк. Барлык орлыклар, шул исәптән шикәр чөгендере, кукуруз һәм көнбагыш симәнәләре тулысынча кайтып бетте, – диде безгә министрлык вәкиле.

Димәк, язгы кыр эшләренә тыныч күңел белән тотынырга җирлек бар дигән сүз. Республикада беренчеләрдән булып җаваплы эшкә тотынган Зәй игенчеләре дә авырлыклар турында сөйләргә яратмый. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Фәргать Камалиев әйтүенчә, кырга беренче трактор 12 апрельдә кергән. Әлеге көндә күпьеллык үләннәрне тукландыралар. Шушы бер-ике көн эчендә бу этапны башкарып чыгарга планлаштыралар. Чиратта – уҗым культураларын тукландыру.

– Авырлыклар бар дип әйтеп булмый. Барысы да тәртип белән бара. Арпа, бодай, көнбагыш, рапс, горчица, шикәр чөгендере, кукуруз орлыклары – барысы да кайтты. Барлык техника да төзек. Дөрес, быел механизаторларга техникага карата тагын да сакчыл булырга туры киләчәк. Күпчелек хуҗалыкларда «Агросила» агрохолдингы эшли. «Союз-агро» җәмгыятенең 3000 гектарга якын җире бар. Анда быел беренче тапкыр көзге арыш чәчәргә уйлыйлар. Узган елларда бу җирләрдә башка культуралар утыртыла иде, – ди Фәргать Камалиев.

Зәй районында шикәр чөгендерен 8900 гектарда чәчәргә уйлыйлар. Узган ел белән чагыштырганда, 600–700 гектарга азрак. Җитәкче аңлатуынча, бу ул мәйданнарга арыш чәчелүгә бәйле.

– Һәр елдагыча, тырышып эшләгән игенчеләргә хөрмәт тә, игътибар да зурдан булачак. Акчалата премияләр дә, кыр батырына тәгаенләнгән «Лада Гранта» машинасы да булыр, дип торабыз. Шунысы мөһим: быел игенчеләрнең хезмәт хаклары да бик әйбәт булачак, – дип ышандырды идарә башлыгы.

«Без әзер!»

Агрохолдинглар, эре хуҗалыклардан кала, республика авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүдә фермерларның да өлеше зур. Алар 543255 гектар җирне эшкәртә. Бу – республикадагы гомуми мәйданның 28 проценты дигән сүз. Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе рәисе Камияр Байтимеров әйтүенчә, бүгенгә алар барысы да язгы кыр эшләренә әзер.

– Заводлар ашламаларны әзерләп өлгерми, шуңа күрә запас тупламыйча, килгән берен куллана торырбыз, дип уйлыйм, – ди ул. – Фермер хуҗалыкларының 98 процентында техника эшкә әзер. Ә менә корткычлардан саклау чаралары белән авырлыклар килеп чыгарга мөмкин. Чөнки аларның күпчелеге чит илдән кертелә иде. Әлеге вакытта министрлык бу мәсьәлә буенча башка илләр белән сөйләшүләр алып бара. Аннан соң Татарстанның үзендә дә биологик саклау чаралары бар. Аларны да кулланырга туры килер, мөгаен. Фермерлар алдында җаваплылык бик зур. Җирне буш калдыра торган чак түгел.

Ахыры 2 нче биттә >

Балаларга – 505 миллиард сум

Быел Россиядә кереме аз булган балалы гаиләләргә 505 миллиард сум бирү күздә тотыла. Премьер-министр Михаил Мишустин белдергәнчә, пособие күләме төбәккә һәм гаиләнең финанс хәленә бәйле, уртача – 6–12 мең сум.

Май аеннан башлап, 8–17 яшькә кадәрге балалары булган аз керемле гаиләләрнең һәркайсына пособие түләнәчәк. Аның күләме төбәктә бала өчен билгеләнгән яшәү минимумының 50, 75 яки 100 процентын тәшкил итәргә мөмкин.

Моннан тыш, бу атнада Президент Владимир Путин керемнәре 1 марттан соң нык кимегән балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларын алуны җиңеләйтергә кушты. Шулай ук дәүләт башлыгы Министрлар Кабинетына пенсияләрне, социаль түләүләрне, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын арттыру турында 20 апрельгә кадәр тәкъдимнәр кертүне йөкләде.

БДИ нәтиҗәсе – порталда

БДИ тапшыручыларга быел имтихан нәтиҗәләрен Дәүләт хезмәтләре порталыннан карау мөмкинлеге ачыла. Рособрнадзорның матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләрен «Документы» бүлегенең «Образование» бүлекчәсенә кереп яки мобиль кушымта аша белергә мөмкин булачак. Порталга барлык төбәкләрдәге укучыларның имтихан нәтиҗәләре чыгачак. Хәзерге вакытта анда БДИны вакытыннан алда бирүчеләрнең мәгълүматлары кертелә. Имтиханны төп чорда бирүчеләр дә күпме балл җыюларын порталга кереп карый алачак. Шулай ук Рособрнадзор сайтында да БДИ нәтиҗәләре белән танышу сервисы эшләвен дәвам итә.

Исегезгә төшерәбез: имтиханнар бирүнең төп чоры 26 май – 2 июль аралыгына туры килә. Быел барлыгы 733 мең чамасы егет-кыз БДИ бирергә ниятли.

60 машина чүп җыелган

Татарстанда федераль юлларның тирә-юне, тукталышлар, ял мәйданчыклары җыештырылып, барлыгы 121,5 тонна – 60 йөк машинасы чүп җыеп алынган.

Моннан тыш юл билгеләре, яктылык кайтаргычлар, киртә-коймалар, җәяүле сукмаклары, мәгълүмат такталары, тавыштан саклау экраннары кышкы пычрак-тузаннан чистартыла, ватык светофорлар һәм башка техник чаралар тәртипкә китерелә, дип хәбәр итә «Волго-Вятскуправдор» матбугат хезмәте. Чистарту-җыештыру эшләренә көн саен 120 эшче, 45 берәмлек техника җәлеп ителә. Ә инде көннәр тәмам җылынгач, юллардагы сызыклар яңартылачак, тиешле буяу эшләре башкарылачак.

Инфляция кими

Республикада март аенда инфляция 9 процент тәшкил иткән. Ел башыннан бу күрсәткеч 11 процентка җиткән инде. «Татарстанстат» мәгълүматларына караганда, бер ай эчендә азык-төлек бәясе 7,2 процентка арткан. Беренче квартал йомгаклары буенча, ризык 10,4 процентка кыйммәтләнгән. Ә инде сәнәгать товарлары хакы узган айда – 12,1, ел башыннан исәпләгәндә, 13,4 процентка үскән. Хезмәт күрсәтүләргә килгәндә, мартта – 6,5, ел башыннан – 8,2 процентка кыйммәтрәк.

Моңа кадәр Россия Хисап палатасы башлыгы Алексей Кудрин 2022 ел буенча инфляциянең 17–20 процент чамасы булачагын фаразлаган иде.

Ун көннең җидесе – ял

1 Май – Яз һәм Хезмәт бәйрәме, 9 Май – Җиңү көне булу сәбәпле, бу айда безне өстәмә яллар көтә. «Россия Хезмәт кодексы нигезендә, 1 һәм 9 Май бәйрәм көннәр булып тора. Бәйрәм ял көненә туры килгәндә, ял киләсе эш көненә күчерелә. Быел 1 Май якшәмбегә туры килә. Шуңа якшәмбе ялы 2 майга, дүшәмбегә күчә», – диелгән Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте хәбәрендә.

Татарстан Президенты Указы буенча, 2 май – Ураза гаете дә бәйрәм көн булып тора. Әмма ул республика бәйрәме булганга, өстәмә ял бирелми.

Моңа кадәр, Россия Хөкүмәте карары нигезендә, 1 гыйнвар шимбә ялы – 3 майга (сишәмбе), 2 гыйнвар якшәмбе ялы 10 майга (сишәмбе) күчерелде. Димәк, 1–3 май һәм 7–10 май көннәрендә ял итәчәкбез.

COVID-19

Чиргә каршы

РЕВАКЦИНАЦИЯНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ ТУРЫНДА ТӨП СОРАУЛАРГА ҖАВАП

Ясатып эш бетми әле. Барыбыз да белгәнчә, коронавируска каршы вакцина ясатучыларга, билгеле бер вакыт узганнан соң, кабат кадату киңәш ителә.

Бу кагыйдәне үтәмәүчеләр дә бар. Соңгы мәгълүматлар буенча, республикадагы кабат вакцина ясатучылар саны – 288 мең тирәсе. Якынча 900 меңнән артык кеше ревакцинация узарга тиешле саналса да, калганнары төрле сәбәпләр белән прививка кадату пунктларына килергә бик ашкынмый. Сүз уңаеннан, Татарстандагы чиргә каршы күмәк иммунитет күрсәткече дә 47 процентка гына калган.

Ревакцинация нәрсә өчен кирәк? Кайда ясатырга? Халыкны кызыксындырган төп сорауларга Татарстанның баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов җавап бирде.

КАЙДА һӘМ НИЧЕК?

Хәзерге вакытта теркәлү урыны буенча медицина оешмаларында вакцина ясатырга мөмкинлек бар. Прививкага язылуның берничә төре барлыгын искәртик:

- Дәүләт хезмәтләре порталы аша;
- «122» номеры аша;
- сырхауханәгә шалтыратып;
- uslugi.tatarstan.ru сайтында;
- Күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итеп.

Прививка кадатырга килгәндә, үзегез белән паспорт, СНИЛС һәм медицина иминиятләштерүе полисын алырга онытмагыз.

1. Ревакцинация ни өчен шулай мөһим? Ревакцинацияне, вакцина ясату турындагы белешмә булуга карамастан, ярты ел саен узу кирәк. Белешмә бирделәр дә, бер елга (белешмәнең гамәлдә булу вакыты – 1 ел. – **Авт.**) барысын да онытып торырга ярый дип уйлау дөрес түгел. Ревакцинациянең акрын баруына да менә шундый уйлар сәбәпче. Чир беркая да китмәде. Сәламәтлек турында онытмасак иде. Белешмә ул – кәгазь генә. Аннан соң авыр булмасын – ревакцинация узу менә ни өчен кирәк. Вакцина ясаткач барлыкка килгән иммунитет организмны ярты еллап кына саклый. Белешмә генә аның күрсәткечен күтәрмәс бит инде. Вирусның моңа исе китми. Барлык фәнни тикшеренүләр дә кабат вакцина ясатуның чирнең авыр очраклары һәм чирдән үлүчеләрнең кимүенә йогынты ясавын сөйли.

2. Ревакцинацияне кемнәр узарга тиеш? Бу җәһәттән хроник авырулары булган кешеләргә һәм өлкән яшьтәгеләргә аерым игътибар бирергә кирәк. Кабат вакцинация ясату антитәнчекләр артуга китерә, шуңа күрә алты ай саен аларны куәтләп торырга кушалар да.

Күпләр: «Вакцина ясаттым да авырдым», – ди. Әлбәттә, бу – мөмкин хәл. Чөнки иммунитет формалашсын өчен, кимендә 21 көн кирәк.

3. Чиргә каршы нинди чараларны үтәү мөһим? Алар үзгәрешсез калды. Вакцина ясату, битлек кию, дистанция саклау. Вазгыять тотрыклырак. Әмма бу давыл алдыннан була торган тынлык булмасын, дип куркам. Көн саен инфекция йоктырган 250ләп кешене теркибез. Күзәтергә, күзәтергә кала. Һәм, әлбәттә, саклык чараларын күрергә. Вакцинация узу өчен кулай вакыт.

Сүзгә-сүз

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Президенты:

Кайбер илләр, Россия хәзерге сәяси позициядә торырга тиеш түгел, дип саный. Ләкин ислам дөньясындагы күп илләр ул фикер белән килешми. Алар безгә теләктәшлек күрсәтә. Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү чит ил партнерларыбыз, дин кардәшләребез белән берләшү мөмкинлеген бирә. Чөнки ул – татарстанлылар һәм россиялеләр өчен генә түгел, ә бөтен ислам дөньясы өчен зур вакыйга.

«Tatarstan Today» тапшыруына биргән әңгәмәсеннән

СЕЗ БӘХЕТЛЕМЕ?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләргә шул сорауны биргән. Җаваплар түбәндәгечә.

Ниндидер мәгънәдә бәхетле	83%
Чын-чынлап бәхетле	37%
Бәхетсез	14%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Ялтырау һәм калтырау

Без шактый мактанчык һәм кыланчык заманда яшибез. Социаль челтәрдә кая барганыңны, нәрсә кигәнеңне, нинди ризык ашаганыңны бөтен дөньяга чыгарып селкемисең икән, син заманнан артта калган, кешечә яши белмәгән бер мәхлук саналасың. Көндәлек тормыш-көнкүрештә дә әледән-әле ялтырап алу, булыр-булмас уңышларны күперту, бик үк хаҗәте булмаган «уенчыклар» җыеп, шулар белән масаю, «важный»лыгыңны ассызыклап тору модада.

«Акыллы атын мактар, юләр – хатынын, шыр тиле үзен мактар» ди татар мәкале. Мактану, үз-үзеңә артык югары бәя кую – ул гел сүзгә генә кайтып калган очракта да, фикер белдерүнең, мөнәсәбәтләрнең әмәтсез бер формасы, акылда артык ерак китмәгәннәр шөгыле. Акыллары шул сайлык сәбәпле, халыкның билгеле бер өлеше андый хакыйкатьне аз гына да аңламый. Шапырыну – чәченнән тартып, үзен сазлыктан чыгарган мәгълүм барон Мюнхгаузен төсле, үзеңне үзең үк күтәрергә алыну һәм, әлбәттә инде, көчсезлек билгесе. Көчле һичкайчан мактанмый. Көчлене көчле икәнен, уңыш-казанышларын, ул аны тирә-якталыларга әледән-әле тукып, күрсәтеп тормаса да, күрәсе кеше күрә. Куркадый кабарып хаҗәт юк, реклама кирәкми. Мактанчык исә булыр-булмас малы, тулыр-тулмас казанышлары белән даими шапырынмыйча түзә алмый. Өлкән туганда шаярнак шундый сүз дә бар бит әле: «Сам себя не похвалишь – как оплеванный ходишь», – диләр. Бу – нәкъ менә мактанчыклар шигаре инде.

Әйбер белән мактану тел белән күпереүгә караганда да ямьсезрәк. Бала-чага бакча яшендә үк башкаларда булмаган уенчыгы белән мактанырга өйрәнә хәзер. Бераз үсеп, урта сыйныфларга йөри башлагач, кулында адәм рәтле смартфоны булмаса, мәктәпкә барасы да юк: тәнәфес саен чукып, мыскыллап торачаклар. Чөнки анда ярыш – кемнең гаджеты шәбрәк тә, кемнеке «отстой». Мәктәп дигәннән, без үскәндә, халык чагыштырмача тигез яшәсә дә, борын чөю барыбер юк түгел иде. Югары сыйныфларда укыган чак. Бездән аз гына өлкән бер егет кисәгенең өендә телевизоры (телевизор сирәк заман), атланып йөрергә атасының мотоциклы һәм кул сәгате бар. Бу кадәр мал-мөлкәт, күрәсең, аның телен гел кычыттырып торган. Югары пилотаж күрсәтеп, катлыкатлы итеп мактанганы истә: «Мотоциклда очып кайтып, өйгә кереп, телевизорны кабызсам, вакыт тәгәл өч – сәгатьне дәреслә торасы да булмады».

Мактануның әле тагын «кыланчыклык» дигән төре бар. Сезнең «дембель атлавы» (дембельская походка) дигән сүзтезмә ишеткәнегез бармы? Армия хезмәтен тәмамлап кайткан егерме яшьлек егетнең «гражданка»дагы беренче көннәрдә үз-үзен тотышын, кыланмышларын күргәнегез бармы? Һәммәсенең дә димим, күбесенең. Нәрсә тагын, ни асып бүлә – барысы да асылган солдат формасы әле өстә, салынмаган. Аякны җилкәдән дә киң итеп аерып атлап, гәүдәне як-якка вәкарь белән генә чайкап, дембель дигәнебез урам буйлап бара. Кыяфәт шундый: ул гүя әле кичә генә Берлинны алып кайткан. Тагын бер айдан ул, әлбәттә, башкача атлаячак. Ә әлегә масайган караш, ирәюле сөйләм: урам гына түгел, бар дөнья – аның аяк астында. Кызык кыланчыклык ул ефрейторның генералча кылануы. Андыйга тагын 90 нчы елларга кура җиләк төсендәге пиджак хуҗаларын да кертеп булыр иде. Муенда юан алтын чылбыр, машина ачкычы кулдан кулга күчеп тора – капитализмга керүгә барлыкка килгән кыланмышлар, «яңа урыслар» дип аталган кавем исегезгә төштеме?

Яшьрәкләрнең андый кәмитен аз-маз аңлап булганда да, акыл теше чыкканнарның кикрик кабартуын кабул итү кыен. Заманалар авыр, еллар ябык вакытларда бер авыл абзые, урам як утыргычка чыгып утырып, гелдән-гел юка чыра кисәге белән тешен каезлый, чистарта торган булган. Янәсе, ул ит ашаган. Имеш, ул хәлле, әйбәт яши. Чынлыкта ит тәмен инде күптән онытып, еллар буе тилмергән. Русча мондый кыланмышны имитация дип атап булыр иде. Пычагым да өстенлек булмаган көе өстенлегеңне күрсәтергә алыну. Бу җәһәттән әле тагын соңгы араларда популярлашкан «нищеброд» атамасы да бар. Анысы да – шул булмаган итне чокып утыру инде. Ягъни ялангач көе төрле ысуллар белән үзеңне бай итеп күрсәтергә алыну, шуннан канәгать калу.

Мисаллар җитәрлек. Рәтле торагы булмаган килеш, алагаем чит ил машинасында йөргәннәр бар, кредитка миллионнар алып, 100–150 кеше җыеп, өчәр көн туй уткәргәннән соң «доширак» ашап яшәгәннәр, кирәге бармы, юкмы, соңгы мода «айфон» электереп, шуның белән шапырынганнар. Агаргын юрганга карап сузмаганнар барысы да – шул «нищеброд» инде. Бу кыланмышлар, «понты» дип аталган бу ялтырау, үзеңне күтәрергә тырышу өстенә, кеше күрсен дә кызыксын, көнләшсен дип тә башкарыла. Һәм көнләшәләр дә. Андый нәрсә бүген йогышлы чир кебек. Синең интернет аккаунтында Төркиядә йә Кипрда төшкән селфи-мелфилар юк икән, син инде – бер мескен. Син, кредит алып булса да, ул тарафларны урап кайтырга, фотоларыңны шәхси сахифәңә эләргә, гавамга күрсәтергә тиешсең. Эшкуар исеме күтәреп тә арзанлы иномаркада йөрисеңме? Димәк, син уңышлы зат, дәрес эшмәкәр түгелсең. Синең ишеләр әнә ким дигәндә кроссоверда чаба. Аңламаячаклар сине... Ә капиталистик мөнәсәбәтләр өчен, кемнәрнеңдер чиктән ашкан табышы өчен халыктагы андый кыланулар, андый эпидемия – бал өстенә май. Чөнки кешедә мөмкинлек, кирәклек бармы, юкмы, кыйммәтле товар сатыла, китә тора.

Мактану һәм кыланчыклыкны хуп күргәннәрнең, бай булып, уңышлы булып күренергә яратканнарның башкалардан тәп аермасы, ихтимал, аларның бары матди әйберләр белән генә кызыксынуында. Андыйлар җир йөзендә «рухи байлык» дип аталган хәзинәнең барлыгын белми, белергә дә теләми. Ярар, сыйныфта смартфоны булмаган бала белән берсе дә дусլашмасын, аны бер бичара санасыннар да. Рухият сабый чакта әле аңлаешлы әйбер түгел. Тик менә кырык, иллене узып та, ул өлкәне белмәү, күрмәү, күрергә теләмәүне, затсыз көе бай һәм затлы булып күренергә тырышуны ничек аңларга? Бит булган акчаны акыллы кеше ялтырауга түгел, үсешкә, хаҗәткә тота.

Мактанчык, кыланчыклар – бәхетсез кавем. «Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндыра». Алар – чыра яндырып яшәүчеләр, имитация осталары. Кеше ни диәр, дип хафаланып, калтырап яшәүчеләр. Чын шәхес, акыллы кеше беркайчан да ялтырау юлы белән дәрәҗәсен арттырырга алынмый. Аның тормышта үз кыйбласы һәм дөрес кыйммәтләре була. Акыллары булган башкалар да аны нәкъ шуның өчен бәяли.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ВАТАН ХАКЫНА

Даны онытылмас. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов контракт буенча хезмәт иткән, Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булган ефрейтор Дамир Гыйлемхановны соңгы юлга озатуда катнашты. Хушлашу чарасы Казан танк училищесы клубында узды.

Иң элек генерал-майор Рөстәм Миңнекаев Россия Президентының Дамир Гыйлемхановка Россия Герое исеме бирү турындагы указын укыды. Дәүләт бүләген хәрбинең гаиләсенә тапшырдылар.

Кешелеклелек үрнәге, тугры иптәш, үз эшенең остасы. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов хушлашу сүзендә Дамир Гыйлемхановны шушы сүзләр белән тасвирлады.

– Украинадагы хәрби операция дәвам итә. Безнең илнең батыр сугышчылары Донбасс халкын яклый, җинаятьчел режим белән көрәшә, Россиянең куркынычсыз киләчәге өчен изге бурычын үти. Татарстанда туып-үскән солдатлар һәм офицерлар да батырлык күрсәтә. Ватанга һәм аның халкына хезмәт итү юлын сайлагач, хәрбиләр еш кына дөньяны үз гомерләре бәрабәренә яклый. Бүген менә Дамир Гыйлемхановны соңгы юлга озатабыз, – диде республика Президенты. – Хезмәттәшләре өчен ул ышанычлы иптәш, профессиональлек һәм кешелеклелек сыйфатлары үрнәге булды. Без якташыбыз күрсәткән батырлыкны онытмабыз. Мин мәрхүмнең якыннарының кайгысын уртаклашам. Бу – сезнең гаилә, безнең республика һәм тулаем илебез өчен зур югалту. Әмма бу батырлык онытылмас.

Хушлашуда һәлак булган егетнең әтисе Рәшит Гыйлемханов: «Улым һәрвакыт: «Сез минем белән горурланачаксыз», – дип әйтә иде», – диде.

Мәрхүмне «Курган» зиратында җирләделәр.

tatarstan.ru

Алмаш табарга кирәк

Импортка алмаш табарга, коронавируска бәйле вазгыятьне кулдан ычкындырмаска, халыкны тыңларга. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов районнар белән видеоэлемтә аша киңәшмә вакытында шушы мәсьәләләргә басым ясады.

Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә Татарстан Президенты чит ил продукциясенә алмаш эзләү бурычы торуын кабат искәртте. Сүз үҗәннән, республиканың маркетинг үзәге элек чит илдән сатып алынган продукцияләр каталогын булдырган. Хәзер менә шуларга алмаш табу тәкъдимнәрен өзерлиләр. Министрлыкларга һәм районнарга маркетинг үзәге белән эшне көчәйтергә йөкләмә бирде Президент.

– Иң мөһим бурычларның берсе – импортны алыштыру, – диде ул. – Каталог зуррак булган саен, безнең предприятиеләр өчен импортны алыштыру мөмкинлекләре күбрәк.

Утырышта Рөстәм Миңнеханов коронавируска бәйле вазгыятькә тукталды. Соңрак җәмәгать урыннарын тәэсләндерү, аларны тәртиптә тоту мәсьәләсен күзатты. «Халык мәнфәгатьләрен исәпкә алырга кирәк», – дип, күпфатирлы йортларның ишегалларына да игътибар итәргә кушты ул.

Президент Бөек Җиңүнең 77 еллыгы якынлашуны да искәртте. «Бәйрәм кысаларындагы чараларны югары дәрәҗәдә үткәрергә кирәк. Без геройларыбызны хәтерләргә, ветераннарыбызны, тыл хезмәтчәннәрен онытмаска тиеш», – диде.

Хәерле сәгатьтә!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Арча районының Корайван авылы фермеры Фәнис Әхмәтханов әйтүенчә, алар кыр эшләренә якынча бер атнадан керешергә уйлыйлар. 356 гектар җиргә арпа, бодай, арыш, печән чәчәргә җыена. Моннан тыш, 50 баш мөгезле эре терлеге бар.

– Барысы да әзер. Җирнең өлгерүен генә көтәбез. Кәефләребез да яхшы. Быелга борчылырлык сәбәп күрмибез. Эшләрен туктаткан яки бөтенләй куркуга калган кеше дә юк. Узган елгы запаслар бар бит, шуларга өмет баглыйбыз. Орлыкны үзебез көздән үк әзерләп куйган идек. Алары тулысынча җитә. Техниканы 2020 елда яңарттык, быел да яңаларын алырга планыбыз бар иде. Ләкин бәяләр күтәрелү сәбәпле, сабыр итәргә булдык. Ашламалар белән дә авыррак. Узган елгы шикелле күпләп алып куеп булмады, кыйммәткә чыкты. Шунлыктан азрак куләмдә кертәләчәк, – диде фермер.

Кукмара районының Олыяз авылындагы «Лена Галиева» фермер хуҗалыгы да кыр эшләренә әзер. Алар якынча ике атнадан соң керешергә уйлыйлар. Хуҗалык башлыгы Рафис Галиев әйтүенчә, аларның 300гә якын терлеге бар. Чәчүлек җирләре дә шактый. 450 гектар. Күбрәк мәйданга кукуруз, арпа, сенаж культураларын чәчәләр.

– Кукуруз буенча бераз куркып торган идек – шөкер, ала алдык. Калган симөнәләр дә әзер. Техникаларны быел яңарта алмадык. Бәяләре 1,5 тапкыр артты бит. Ләкин бу сезонга җитәчәк, начар халдә түгел. Дүшәмбе 30 тонна ашлама алып кайтсак, анысы да булачак, – диде ул. – Кырларда кар ятә әле. Көннәр матур торса, май башларында чыгарбыз дип торабыз. Узган елгы кебек корылык кына булмасын иде. Юкса бик начар булган иде. Быелга зур өметләр баглыйбыз.

Кем белән генә сөйләшсәк тә, күр тавыш белән кыр эшләренә әзер булуларын әйттеләр. Шунысы сөендерә. Инде еллар уңышлы килсен иде дә, игенчеләр тырышканнарының матур әҗерен күрсеннәр иде, дип телик.

ҮЗ КӨЧЕҢӘ ТАЯНЫР ЧАК

Атна-ун көннән республикада кызу төзелеш сезоны башланачак. Төзүчеләр исә бүгеннән үк аның ахыры турында уйлана. Киләчәк һәрчак куркыта. Килеп туган вазгыятьтә бигрәк тә. Татарстан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илдус Насыйров сүзләренә караганда, республикада быелгы сезонга планлаштырылган төзекләндерү эшләре график буенча барачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Тиздән кызу төзелеш сезоны башланачак. Ул шактый кыска. Сентябрь башына инде социаль, мәдәният тармагында планлаштырылган барлык төзекләндерү эшләре тәмамланырга тиеш», – диде ул журналистлар белән очрашуда.

Илдус Насыйров сүзләренә караганда, «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында республикада 66 объект төзекләндереләчәк. Бүген шуларның 21ендә эш башланган инде. «Аларны яңа уку елы башланганчы өлгертергә кирәк. Укытучыларыбыз, укучыларыбыз яңа, чиста, төзек сыйныф бүлмәләренә килерлек булсын», – ди министр урынбасары. Моннан тыш, Татарстанда тагын 141 белем бирү объекты яңартылачак. Шуларның 90ы – муниципаль, 29ы – кадет мәктәбе. 22 балалар бакчасына да яңа сулыш өреләчәк. Белем бирү оешмалары белән беррәттән, быел Татарстанда 167 мәктәп ашханәсе, 7 тулай торак корпусы белән 11 урта һөнәри белем бирү оешмасының бинасын да төзекләндерергә җыеналар.

Сәламәтлек саклау оешмалары да яңарачак. Илдус Насыйров сүзләренә караганда, пандемия чорында бу өлкәдәге төзекләндерү эшләрен икенче елга да күчереп торырга туры килгән. «Мондый объектларда төзекләндерү эшләре алып бару кыенрак. Тулы бер кат яки оешманың бер өлешен бушатырга кирәк. Шул ук вакытта без авыруларга да уңайсызлык тудырмаска, төзүчеләрнең сәламәтлегенә дә зыян салмаска тиеш. Быел бу яктан җиңелрәк булыр дип өметләнәбез», – ди ул. Министр урынбасары китергән саннардан аңлашылганча, «Сәламәтлек саклау» федераль проекты кысасында быел республикада 15 сәламәтлек саклау оешмасы төзекләндереләчәк. Аерым алганда, аның кысасында Лениногорск, Зәй, Яшел Үзән, Алексеевск, Кукмара, Теләче, Аксубай районы хастаханәләре яңартылачак. Бу эшкә 245 миллион сум акча сарыф ителәчәк. Моннан тыш республика казнасы хисабына 33 стационар белән 15 хастаханә дә төзекләндереләчәк.

Быел Татарстанда 11 яшүсмер клубын да төзекләндерергә җыеналар. Моның өчен 100 миллион сум акча сарыф ителәчәк. Планлаштырган эшнең беренче нәтиҗәләре дә күренә башлаган инде. Бу көннәрдә Апас районындагы яшүсмерләр клубында төзекләндерү эшләре тәгәлләнгән. «2014 елдан бирле республикада балалар сәламәтләндерү лагерьларын төзекләндерү эше да алып барыла. Быел шундый 6 лагерь төзекләндереләчәк. Аңа 390 миллион сум акча сарыф ителәчәк. Яшьләр һәм яшүсмерләргә психологик ярдәм күрсәтүче 15 объект та яңартылачак. Моннан тыш, республикада 23 спорт объекты да төзекләндереләчәк. Бу максатта 500 миллион сум акча сарыф ителәчәк», – ди министр урынбасары.

Татарстандагы мәдәният учакларын да үзгәрешләр көтә. Аерым алганда, быел республикада 370 миллион сумга район мәдәният йортлары төзекләндереләчәк. «Ремонттан соң алар тулы куәткә эшләргә тиеш. Юкса күп җирдә бу эш тиешенчә башкарылмый. Бигрәк тә авыл җирлегендә. Күп кенә авыл клублары шимбә һәм ял көннәрендә генә ачыла», – ди Илдус Насыйров.

Күреп торабыз: быел төзү, төзекләндерү эшләре катлаулы шартларда башкарылачак. Санкцияләр төзелеш материаллары тармагына да бәрде. Аларның хаклары, яшен тизлегендә үсеп, 2–3 тапкыр артты. Әмма Илдус Насыйров төзелеш материалларын тора-бара барыбер арзанаер дип өметләнә. «Төзелеш материаллары кыйммәтләнү куркыта, билгеле. Бу аеруча чит ил материаллары, кораллары кулланып төзелгән, төзекләндерелгән объектларда сизелергә мөмкин. Әлегә төзелеш тармагы шок кичерә. Әмма бу озакка бармас дип өметләнәм. Төзелеш материалларына сорау кимесә, бәяләрне төшерми хәлләре юк», – ди ул.

Илдус Насыйров төзелештә эшче куллар җитә дип ышандыра. Яшерен-батырын түгел, моңарчы бездәге төзү, төзекләндерү эшләрен, нигездә, Үзбәкстан, Таҗикстаннан килүче арзанлы эшче куллар башкарды. Билгеле сәбәпләр аркасында соңгы елларда аларның саны шактый кимеде. «Аларның сафы быел да сирәгрәк булыр дип уйлыйбыз. Ничек кенә булмасын, һәр эштә үз көчебезгә таянырга кунеккән без», – дип ышандырды Илдус Насыйров.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Камалия» ял итү-үсеш үзәге автоном коммерциячел булмаган оешмасы президенты **Вафин** Радик Газинур улына; «Энергобанк» акционерлык коммерциячел банкы (акционерлык җәмгыяте) идарәсе рәисе **Коннова** Ирина Петровнага; «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе карышындагы Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары **Кочнева** Людмила Николаевнага; «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы» филиалының «Татар-информ» татар редакциясе, «Интертат» электрон газетасы, «Атна вакыйгалары» газетасы баш мөхәррире **Латыйпов** Рәмис Нурмөхәммәт улына; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Азнакай муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Мәрданшина** Элиза Наил кызына; «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиоэлектроника һәм мәгълүмати-үлчәү техникасы кафедрасы профессоры **Нигъмәтуллин** Равил Рашид улына; «ЛИДЕР» мәгариф үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сәйбатталова** Ризида Фәнүс кызына; Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары **Шәрәфетдинов** Рамил Гомәр улына; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы полиция майоры **Курылев** Сергей Владимировичка; «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте «Чистай электр челтәрләре» филиалының ярдәмче станцияләр хезмәте башлыгы **Денисов** Андрей Львовичка; «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең икътисади фаразлау бүлеге башлыгы **Нигъмәтуллина** Руфинә Мөхәррәм кызына; «Уңайлы торак идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Попов** Роман Александровичка; «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Соин** Тимур Игоревичка; Татарстан Республикасы Хисап палатасы гомуми бүлегенең эш башкару секторы мөдире **Волгина** Юлия Николаевнага; «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең транспорт һәм техник тәэминат бүлеге автомобиль йөртүчесе **Галиев** Альберт Зөлкарнәй улына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең оештыру һәм кадрлар эше бүлеге баш белгече **Гаттарова** Наилә Әнвәр кызына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең кадрлар сәясәте идарәсе муниципаль хезмәт эшләре бүлеге башлыгы **Гафарова** Гүзәл Фәрит кызына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең Киров һәм Мәскәү районнары буенча мәгариф бүлеге башлыгы **Ершова** Татьяна Константиновнага; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең сатып алулар бүлеге баш белгече **Остальцева** Ирина Анатольевнага; Казан шәһәре Совет районының «110 номерлы лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең укытучысы мөдире **Подогова** Сиринә Шакирҗан кызына; Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Академик Р.З.Сәгъдиев исемендәге урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тормыш иминлеге нигезләре укытучысы **Сысоев** Сергей Владимировичка; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек секторы мөдире **Яруллин** Илһам Зәкиулла улына; Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Питрәч һәм Балык Бистәсе районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы урынбасары **Фазылҗов** Фәрит Габдулхак улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Рәсми документлар

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында

Хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин итеп, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләренең хәрби-тарихи һәм хезмәт мирасын саклау, шулай ук Бөек Ватан сугышы елларында әлеге предприятиеләрдә эшләгән хезмәткәрләрнең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге турындагы хатирәләрне мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен гамәлгә куярга.

2. «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирү турында таныклыкның тасвирламасын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 12 апрель
№ ПУ-266

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның 12 апрелендәге
ПУ-266 номерлы Указына
1 нче кушымта

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында нигезләмә

1. «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм эшчәнлек алып барган, хезмәткәрләрнең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге нәтиҗәсендә хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин итеп, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләренең хокукый дәвамчылары булган сәнәгать предприятиеләренә (алга таба тиешенчә – республика исеме, предприятиеләр-хокукый дәвамчылар, предприятиеләр) бирелә.

2. Предприятиенең Бөек Ватан сугышы чорында продукция эшләп чыгаруны тәэмин иткәне өчен документлар белән расланган СССР дәүләт бүләге белән бүләкләнүе факты һәм (яисә) предприятиегә Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл байрагы тапшырылу факты һәм (яисә) Бөек Ватан сугышы чорында предприятие хезмәткәрләренең хезмәттәге казанышлары өчен дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүе факты (фактлары) республика исемен бирүгә нигез булып тора.

3. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамә предприятие-хокукый дәвамчы җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты оештырган, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткән предприятиеләр хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге турындагы хатирәләрне мәңгеләштерү мәсьәләләрен карарга вәкаләтле ведомствоара комиссиягә (алга таба – ведомствоара комиссия) җибәрелә.

4. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамәгә түбәндәгеләр теркәп бирелә:

предприятие-хокукый дәвамчы уставы күчермәсе;

предприятие-хокукый дәвамчы хезмәткәрләренең җыелышының, конференциясенең республика исемен бирү турында үтенечнамә бирүгә бәйле эш башлау турында карары кертелгән беркетмә (беркетмәдән өзек);

республика исемен бирү өчен нигез (нигезләр) булуын раслый торган документлар күчермәләре;

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең республика исемен бирү өчен нигез (нигезләр) булуы турында бәяләмәсе.

5. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамә башта территориясендә предприятие-хокукый дәвамчы урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы, шулай ук предприятие-хокукый дәвамчының төп эшчәнлеге рәвешенә туры килгән эшчәнлек даирәсендә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салуны) башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе белән килештерелә. Әлеге килештерү Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә кәгазь чыганакта ирекле формада башкарыла.

6. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамә алынган көннән 30 календарь көн эчендә ведомствоара комиссия аны карап тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

республика исемен бирү турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Президентына мөрәҗәгать итәргә;

республика исемен бирү турындагы үтенечнамәне кире кагарга.

7. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамәне кире кагу өчен нигезле сәбәпләр түбәндәгеләр:

республика исемен бирү өчен нигез булмау;

республика исемен бирү турындагы үтенечнамәдәге һәм аңа теркәп бирелгән документлардагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәве;

республика исемен бирү турындагы үтенечнамәгә теркәп бирелгән документларның тулы булмавы.

8. Республика исемен бирү турындагы үтенечнамәнең кире кагылуы турында ведомствоара комиссия предприятие-хокукый дәвамчы җитәкчесенә, кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге карар кабул ителгән көннән җиде календарь көн дәвамында хәбәр бирә.

Үтенечнамәне кире кагу сәбәпләре бетерелгән очракта, ул кабаттан юлланырга мөмкин.

9. Республика исемен бирү турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Президентына мөрәҗәгать итәргә дигән карар кабул ителгән очракта, ведомствоара комиссия билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына тиешле мөрәҗәгатьне юллый.

Мөрәҗәгатькә түбәндәгеләр теркәп бирелә:
ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсе;

предприятие-хокукый дәвамчының үтенечнамәсе һәм аңа теркәп бирелә торган документлар;

Татарстан Республикасы Президентының республика исемен бирү турындагы указы проекты.

10. Республика исеме Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә бирелә.

11. Республика исеменә лаек булган предприятие-хокукый дәвамчыга Татарстан Республикасы Президенты кул куйган республика исемен бирү турындагы таныклык тантаналы шартларда тапшырыла. Әлеге таныклыкны Татарстан Республикасы Президенты яисә аның йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләре тапшыра.

12. Республика исемен бирү турындагы таныклык бланкларын эшләү, саклау, республика исемен бирү турындагы таныклыкларны әзерләү һәм кул кую өчен Татарстан Республикасы Президентына тапшыру, шулай ук республика исемен бирү турындагы таныклыкларны исәпкә алу Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан башкарыла.

13. Республика исеме предприятие-хокукый дәвамчыга бер тапкыр бирелә. Республика исемен бирү турындагы таныклыкны югалткан очракта, дубликат бирелми.

14. Республика исеменә лаек булган предприятие-хокукый дәвамчының республика исемен ачыктан-ачык файдаланырга, шулай ук үз акчасына эскизы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Мемориаль такталар буенча комиссия тарафыннан раслана торган мемориаль такта ясатырга һәм куярга хокукы бар. Мемориаль такта предприятие-хокукый дәвамчы территориясендә куела.

15. Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм алар карамагындагы предприятиеләр Җиңү көненә, башка истәлекле даталарга һәм бәйрәм көннәренә багышланган тантаналы чаралар уздырганда, аларда катнашу өчен республика исеменә лаек булган предприятие-хокукый дәвамчы вәкилләрен чакыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның 12 апрелендәге
ПУ-266 номерлы Указына
2 нче кушымта

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында таныклыкның тасвирламасы

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирү турында таныклык (алга таба – таныклык) горизонталь А3 (297 х 420 мм) форматындагы ялтыравыксыз ак кәгазь битеннән гыйбарәт.

Битнең алгы ягына бит кырыеннан 10 мм ара калдырып офсет ысулы белән басылган 16,5 мм киңлектәге кыса эченә урнаштырылган бизәк төшерелгән.

Таныклыкның тексты саклагыч тангир челтәрле җирлектә бит кырыеннан 30 мм ара калдырып урнаштырылган куе кызыл төстәге кыса эчендә бирелә.

Битнең өске кырыеннан 45 мм ара калдырып өске якта уртада 26 мм диаметрлы алтын бизәк рәвешендә тыгызлап басылган Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан өстә тиешенчә сул һәм уң якта бер юлга офсет ысулы белән басылган 4 миллиметрлы баш хәрефләрдән: «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» һәм «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» сүзләре урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан аста сул якта «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» сүзләреннән 30 мм ара калдырып алтын бизәк рәвешендә басылган 7 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 4,5 миллиметрлы (юл хәрефләре) хәрефләрдән: «СВИДЕТЕЛЬСТВО о присвоении республиканского звания «ПРЕДПРИЯТИЕ ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ. 1941–1945 ГГ.» сүзләре урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан аста уң якта «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» сүзләреннән 30 мм ара калдырып алтын бизәк рәвешендә тыгызлап басылган 7 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 4,5 миллиметрлы (юл хәрефләре) хәрефләрдән: «ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ. 1941–1945 ЕЛЛАР» республика исемен бирү турында таныклык» сүзләре урнаштырылган.

Битнең сул ягында «СВИДЕТЕЛЬСТВО о присвоении республиканского звания «ПРЕДПРИЯТИЕ ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ. 1941–1945 ГГ.» сүзләреннән 15 мм аскарак 4 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 3 миллиметрлы (юл хәрефләре) куе кызыл төстәге хәрефләрдән түбәндәге текст урнаштырыла:

«Указом Президента Республики Татарстан от «___» ______ 20 _ года № УП- ___ ____________
____
(наименование предприятия)
присвоено республиканское звание «Предприятие трудовой доблести. 1941–1945 гг.».

Битнең уң ягында «ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ. 1941–1945 ЕЛЛАР» республика исемен бирү турында таныклык» сүзләреннән 15 мм аскарак 4 миллиметрлы һәм 3 миллиметрлы куе кызыл төстәге хәрефләрдән түбәндәге текст урнаштырыла:

«Татарстан Республикасы Президентының 20___ елның «___» ___________ ПУ-____ номерлы Указы нигезендә ______________________________________
____
(предприятиенең атамасы)
«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирелде».

Тексттан 15 мм астарак уртада Татарстан Республикасы Президенты имзасы һәм рус телендә – сул якта, татар телендә – уң якта куе кызыл төстәге 4 миллиметрлы баш хәрефләрдән Татарстан Республикасы Президентының исеменең беренче хәрефе, атасының исеменең беренче хәрефе һәм фамилиясе рәвешендә аның имзасының шәрехләмәсе урнаштырыла.

Аскы якта уртада 4 миллиметрлы (баш хәрефләр) һәм 3 миллиметрлы (юл хәрефләре) куе кызыл төстәге хәрефләрдән: «Казань, Кремль» сүзләре урнаштырыла.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыятенең 206 номерлы цехы слесаре-ремонтчысы **Галимханов** Фәрид Шәрифҗан улы; һөнәри эшчәнлектә казанышларга ирешүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының матди-техник тәэминат һәм дәүләт заказы бүлеге әйдәүче белгече **Гатауллина** Резидә Мәхмүт кызы; Татарстан Республикасы Югары Суды администраторы **Киселева** Наилә Хәмит кызы; мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүдәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Горнышева** Айгөл Алмас кызы; халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Апас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең участок табиб-педиатры **Зиатдинова** Наилә Фәрит кызы; «Анатомика» инновацияләрне гамәлгә кертү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Михеев** Альмир Александрович; Питрәч муниципаль районының социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы **Кашапов** Илһам Миңнехан улы; һөнәри эшчәнлектә казанышларга ирешүе һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе башлыгы **Лебедева** Наталья Андреевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «4 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директорының укыту-тәрбия эше буенча урынбасары **Айдашева** Алла Валерьевнага, «Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директорының икътисади һәм гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Мәхмүтова** Диларә Зөфәр кызына, шәхси эшкуар **Старикова** Татьяна Геннадьевнага, язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Турхан** Евгений Андреевичка, шәхси эшкуар **Фәттахова** Анастасия Евгеньевнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Буа шәһәре лицей-интернаты (сәләтле балалар мәктәбе)» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Зыятдинова** Гөлназ Шәйхетдин кызына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Чепья урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Ильясов** Рафаэль Шәрип улына, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 3 номерлы гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Коновалова** Людмила Владимировнага, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Лесхоз урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең химия укытучысы **Корбанова** Сәлимә Әдһәм кызына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Кукмара шәһәренең А.М. Булатов исемендәге күппрофильле лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы **Мәхмүтова** Люция Петровнага, «Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең технология укытучысы **Митюшкина** Ольга Геннадьевнага, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Могыйзов** Марат Әмир улына, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының С.К. Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология һәм химия укытучысы **Хәбибуллина** Фәридә Котдус кызына, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең химия укытучысы **Хафаева** Раушания Мөхәммәт кызына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Нырсы урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Чернов** Петр Александровичка, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Олыяз лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Якупов** Рәсүл Әхәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Республиканың суд системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе **Гыйлаҗев** Илгиз Идрис улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Бөгелмә муниципаль районы буенча Бөгелмә шәһәреннән тугыз бала анасы **Газизуллина** Наталья Анатольевна, Кукмара муниципаль районы буенча Арпаяз авылыннан биш бала анасы **Гаптрәхимова** Асия Салих кызы, Лениногорск муниципаль районы буенча Лениногорск шәһәреннән җиде бала (аларның алтысы өч яшькә җиткән) анасы **Борзова** Анна Владимировна **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

«Мәскәү районының торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының капиталь һәм агымдагы төзекләндерү эшләре буенча урынбасары **Ильясова** Эвелина Равил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Стройсервис ТАПС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Гайфетдинов** Илгизәр Габдрахман улына, «Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең техник контроль бүлеге төзелеш эшләнмәләре һәм материаллары контролеры **Исакова** Ирина Дмитриевнага **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз беренче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз беренче утырышын 2022 елның 21 апрелендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 14 апреле
№ 1402-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз беренче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз беренче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

3. 2021 елда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында хисап.

4. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан 2021 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелгән чаралар турында мәҗбүри гавами хисабы.

5. «2021 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының хәле һәм аларны үстерү турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы доклады.

6. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 22 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 288-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 287-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 284-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 283-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 286-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 289-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» 291-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» 290-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» 285-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 78299-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Бердәм дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гомуми җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә).

16. «Күпфатирлы йортлар һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 77890-8 номерлы федераль закон проекты хакында (өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча таләп итү хокукы бирү шартнамәсен дәүләт теркәвенә алу турында).

17. «Россия Федерациясе Тимер юл транспорты уставы» Федераль законның 83 статьясына үзгәреш кертү хакында» 94415-8 номерлы федераль закон проекты турында (шәһәр яны поездларында 7 яшькә кадәрге балаларны түләүсез йөртү хакында).

18. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 83061-8 номерлы федераль закон проекты хакында (озак сроклы инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру һәм аларның хосусый инвесторлар өчен инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру өчен дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерү өлешендә).

19. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 95 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 84812-8 номерлы федераль закон проекты турында (җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга контрактларны үзгәртү механизмын төгәлләштерү өлешендә).

20. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 72939-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт (муниципаль) учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затлар өчен башка түләүле вазыйфалар биләүне һәм башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнүне тыю билгеләү өлешендә).

21. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76647-8 номерлы федераль закон проекты хакында (коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге законнарны камилләштерү өлешендә).

22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 89661-8 номерлы федераль закон проекты турында (күмерне күчерү, ваклау һәм сортларга аеру эшчәнлеге өлкәсендәге күрсәтмәләрне үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

23. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 85708-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Сколково» инновация үзәге территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан югары квалификацияле фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләүне, гыйльми дәрәҗәләр бирүне камилләштерү өлешендә).

24. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 86110-8 номерлы федераль закон проекты турында (гамәли әзерлек оештыру өлешендә).

25. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары биналарын капиталь ремонтлауның федераль программасын эшләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А. Голиковага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 14 апреле
№ 1403-VI ДС

Мин кулыма китап алам...

Балаларга – сөенче

Биш төрле өлкә турында иң кызыклы мәгълүмат. Татарстан китап нәшриятында яшь китап сөючеләр өчен гаҗәеп матур һәм файдалы энциклопедияләр басылып чыкты. Бу хакта Татарстан китап нәшриятының генераль директоры Илдар СӘГЪДӘТШИНнан сораштык.

:: Энциклопедия нәшер итү идеясе ничек барлыкка килде?
– Мәскәүдәге РОСМЭН нәшрияты белән берлектә эшләнгән әлеге проект Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә тормышка ашырылды. Энциклопедияләребез файдалы һәм матур. Аларда бик күп мәгълүмат һәм фотосурәтләр тупланган. Һәр китап тәкъдим ителгән теманы тирәнтен өйрәнергә ярдәм итәчәк. Энциклопедиядә мәгълүмат гади һәм аңлаешлы телдә бирелгән. Сүз уңаеннан, былтыр балалар бакчаларына йөрүче балалар өчен энциклопедияләр эшләгән идек. Анысын да комиссиябез ярдәме белән башкардык.

:: Китаплар нинди өлкәләргә багышланган?
– Хәзерге вакытта биш энциклопедия нәшер ителде. Алар футбол, диңгез-океаннар, астрономия һәм галәм, тереклек дөньясына багышланган. Тагын бишесен чыгарасы бар. Бу китаплар бизнес, этләр, бөҗәкләр, авиация, төрле илләр турында булачак.

:: Китап өчен сайлап алган темаларыгыз да үзенчәлекле...
– Энциклопедияләрнең темаларын Комиссия белән берлектә сайладык. Уйлашканда, барыннан да бигрәк, хәзерге заман балаларының кызыксынулары исәпкә алынды. Һичшиксез, бу китапларны укып, бала әйләнә-тирә дөнья турында күп кенә файдалы һәм кызыклы белемнәр туплаячак. Китаплар өчен текстларны тәрҗемә итү эшенә дә чын профессионалларны җәлеп иттек. Әйтик, Атлас Гафиятов – «Футбол», Ләлә Сабирова – «Терек табигать», Эльвира Кыямова – «Диңгезләр һәм океаннар», Венера Камалиева – «Астрономия һәм космос», Илсөяр Кадыйрова «Гаҗәеп хайваннар» китапларын тәрҗемә итүдә катнашты. Китап бик җиңел телдә язылды. Аны укырга рәхәт.

:: Әлеге китаплар мәктәпләргә, балалар бакчаларына таратылачакмы соң?
– Китап 6 яшьтән өлкәнрәк балалар өчен дип бара. Урта яшьтәге мәктәп балаларына атап эшләнгән ул. Әлбәттә, энциклопедияләр республика мәктәпләренә таратылачак. Барлыгы өч меңләп данә булыр. Тиражның бер өлеше сатуга да чыкты әле.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сусау

Моннан берничә ел элек: «Гөрләвексез язлар үтеп бара», – дип язган идем. Быелгы яз да шундый булды.

Апрель уртасы җитә инде, әле урамда матур итеп, челтерәп гөрләвек акканы булмады. Юкса кар да күп яуды, эреп тә бара. Соңгы көннәрдә яңгырлары да шактый булды. Әмма канауларда, бакчаларда, басуларда аккан, җыелып торган су юк.

Бездән ерак түгел генә тау бите башлана. Ул әллә ни биек түгел, басуга тоташып, бер авышлык кебек кенә кала. Тик шундагы кечкенә генә ерганак вакыты белән шактый куркынычка әйләнә. Язын бөтен басу кары эреп, көчле сулар төшсә, җәен озакка сузылган яңгырлардан соң да берничә тапкыр якын-тирәләрне су басты. Елның-елында тау итәгендә кары да мул була. Кыскасы, шушындый карлы елда безнең тирәдә гөрләвек агарлык су булмау гайре табигый хәлгә тиң. Җылы, кояшлы көннәрдә исә су, каршы яктагы тирән канауларны тутырып, берничә көн ярсып-сикереп ага, кайчакта тулып ташый, әле аннан соң да атналар буе гөрләвек челтери иде.

Быел кар күп, су каты төшәр, дип көткән идек. Инде тау битләре, басулар кардан арчыла бара. Әлегә чын гөрләвек күрмәдек. Баксаң, эрегән бер кар басуга, җиргә сеңеп бара икән. Хәтта коеп яуган яңгыр сулары да җыелып тормады кебек. Туң тирән түгел, 20–25 сантиметр гына, дигәннәр иде шул.

Без ел саен ишегалдындагы карның яуган берсен бакчага ташыйбыз. Язын боз да булмый, тиз дә кибә. Бакчадагы тау кебек өелгән карлардан эрегән суларны башка елларда ерып җибәрә идек. Быел анда да җыелган су юк. Алар да сеңеп бетеп бара.

Үткән ел җәе дә, көзе дә нык коры килде шул. Җир, мескен, шулкадәр сусаган булган икән! Кар-яңгыр суларын йотлыга-йотлыга сеңдереп, ул, мөгаен, әнә шул кимегән запасларын тутырырга, тереклеген коткарырга тырышадыр. Кышның җылы, карлы килүе дә аңа теләктәш булды, димәк...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Казан федераль университеты җитәкчелеге, укытучылары һәм студентлары, әтисе **ҖАМАЛЕТДИНОВ Рифкать Миргасим улы**ның вафат булуы сәбәпле, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор Җамалетдинов Рәдиф Рифкать улының, гаиләсе, туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

СӨЙЛӘП БУЛМАГАННЫ КӨЙЛӘП БУЛА

«Татнефть»тән – талантларга

Бетховен әсәрләрендәге тормыш фәлсәфәсе, Шопенның шигъри иреге, Бах көйләрендәге гармония бөтенлеге... Шуларның барын да нибары 88 төймә ярдәмендә җиткереп була. Иң мөһиме – бармакларың күңелең белән бергә хәрәкәт итсен. Дөнья күләмендә танылу алган пианистка һәм профессор Мирослава Марченко шул фикердә.

«Татнефть» матбугат үзәге

Бүген фортепиано сәнгатенең дәрәҗәсен күтәрергә, милли фортепиано мәктәбен камилләштерергә кирәк. Әнә шул максатны күз уңында тотып, «Татнефть» компаниясе ярдәме белән, Әлмәттә II Халыкара фортепиано сәнгате академиясе узды. Әлеге проект «Татнефть»нең махсус Гранты нигезендә гамәлгә куелган.

Проект кысасындагы мастер-классларның барысы да Әлмәт музыка көллиятендә узды. Без килеп кергәндә, уку йорты музыка дөньясына чумган иде. Музыка көллияте булгач, исеме җисеменә туры киләдер инде, диярсез. Ләкин ул көнне бирегә аеруча илаһи мохит хөкем сөрде: Россиянең атказанган укытучысы, Мәскәү консерваториясе профессоры Мирослава Марченко музыка әсәрләренең иң нечкә урыннары, серләре турында сөйләде.

– Әлмәткә беренче тапкыр берничә ел элек килдем. Ул чакта мондагы инструментларның сыйфаты бик начар иде. «Татнефть»нең ярдәме сизелә: бүген сәхнәдә «YAMAHA» рояле тора. Компаниядә сәнгатьнең дә нефть кебек алтын дәрәҗәсендә булуын яхшы аңлыйлар, мин моңа бик шатмын, – диде танылган музыкант.

Көнозын дәвам иткән мастер-класслар, Мәскәү кунагы тәкъдим иткән концерт катнашучыларны битараф калдырмагандыр. Бөгелмә, Лениногорск, Казан, Әлмәтнең яшь пианистлары үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап табып кына калмыйча, Мирослава Марченкодан практик дәресләр дә алды.

– «Татнефть»нең финанс ярдәме безгә Татарстанның нефть төбәгендә заманыбызның күренекле музыкантлары белән берлектә фортепиано сәнгатен үстерү идеясен тормышка ашырырга мөмкинлек бирде. Әлеге проект нәтиҗәләре буенча иң яхшы катнашучылар Таруса шәһәрендәге Святослав Рихтер исемендәге җәйге иҗат мәктәбендә катнашу өчен тәкъдим ителәчәк. Мондый мөмкинлеккә ия булучылар Мәскәүнең иң яхшы профессорлары белән берлектә музыка серләренә төшенәчәк, ә соңыннан танылган дирижер Иван Великанов белән симфоник оркестрда уйный алачак, – диде проектның авторы һәм оештыручысы, Әлмәт музыка көллияте укытучысы Әлфия Шиһапова.

Мастер-классларда укучылар һәм студентлар гына түгел, балаларга музыка белеме бирүче укытучылар, остазлар да катнашты. Алар исә Мәскәүдән килгән коллегаларына педагогика юнәлеше буенча сорауларын бирә алды.

II Халыкара фортепиано сәнгате академиясе кысасындагы мастер-классларның чираттагысын Татарстанның халык артисты, күренекле пианист, «Шопен илчесе» Рэм Урасин уздырган. Монысын үзебез күрә алмасак та, көллиятнең актлар залы Казан, Ижау, Можга, Чаллы, Лениногорск, Бөгелмә, Азнакай, Нурлат, Мөслим, Зәй, Сарман, Урыссу, Баулы, Яшел Үзәннән килгән музыкантлар һәм барлыгы 120дән артык укытучы белән шаулап торганны сөйләделәр. Миңа калса, әлеге проектның әһәмиятен шушы саннар да раслый.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЙОЛДЫЗЛАР КАБЫНГАНДА

«СОЗВЕЗДИЕ – ЙОЛДЫЗЛЫК» ФЕСТИВАЛЕНЕҢ ГАЛА-КОНЦЕРТЫ УЗДЫ

«Уникс» концертлар залында «Созвездие – Йолдызлык» XXII ачык республика телевизион яшьләр фестиваленең гала-концерты узды. Концертта конкурсның суперфиналында призлы урыннар яулаган балалар бүләкләнде.

Заманча эстрада сәнгатендә иң зур хәрәкәт булып торган «Созвездие – Йолдызлык» фестивале кабат яңа йолдызлар кабыза. Фестиваль сәләтле яшь башкаручыларны елдан-ел күбрәк җәлеп итә. Быел жюри әгъзалары республиканың 48 районыннан 5000нән артык катнашучы арасыннан чын сәләт ияләрен эзләде. Зона этапларында барлыгы 60 меңнән артык катнашучы 21 меңгә якын иҗат номерлары белән чыгыш ясады. Гала-концертта катнашучылар «Вокал-соло», «Вокаль ансамбльләр», «Хореография», «Конферанс», «Җырга иң яхшы көй», «Иң яхшы җыр тексты» һәм «Иң яхшы видеоклип» номинацияләрендә үз талантларын күрсәттеләр. Фестиваль лауреатларына дипломнар, истәлекле бүләкләр һәм Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановтан дәүләт стипендияләре тапшырылды. 22 апрельдә «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Созвездие – Йолдызлык» фестиваленең йомгаклау гала-концерты узачак. Анда калган җиңүчеләрнең исемнәре, проектның Гран-при ияләре билгеле булачак. Шулай ук, фестивальнең быелгы яңалыгы – Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең махсус призын тапшырачаклар.

– Балаларга бәя бирү бик авыр. Аларның барысы да бертигез түгел, тик алар бөтенесе дә тырыша, бар көчләрен куя. Укытучыдан да күп нәрсә тора. Ул ничек балалар белән эшли, нәтиҗәсе шундый була. Укытучы гына түгел, бала да тырышырга тиеш. Җиңүгә юл озак була ул. Хәзер биеп кенә Гран-при алып булмый, үзеңнең үсешең, осталыгың белән жюри әгъзаларын шаккатырырга кирәк. Мин бу проектта инде 22 ел. Шушы еллар дәвамында башкарылган эшләрнең нәтиҗәсе бик зур. Миллионлаган бала зур фестивальнең бер өлеше булып өлгерде. Бөтен күңелләрен биреп, сәхнәдә үскән балалар мөстәкыйль була, җәмгыятьтә үз урынын таба. Без аларны шулай тәрбияләргә тырышабыз, – диде фестивальнең жюри әгъзасы, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең баш балетмейстеры Раилә Гарипова.

Яшь башкаручылар, биючеләр уңышка ирешсен өчен, укытучыларга да күп хезмәт куярга туры килә. Чөнки уңышлы чыгыш артында – күп сәгатьлек репетицияләр, эзләнү, дулкынланулар. Әлмәтнең «Фристайл» заманча бию студиясен җитәкләгән Максим Апраксин да әзерлек эшенә күп көч салган.

– Безнең коллективта 150дән артык бала шөгыльләнә. Гала-концертта ике кече төркем бүләкләнде, өлкән төркемнәр 22 апрельдә «Пирамида»да узачак йомгаклау концертында бүләкләнәчәк. Барысы да призлы урыннардан башланмады, әлбәттә, мондый нәтиҗәгә акрын адымнар белән килдек. Фестиваль елдан-ел үсә, яңа сулыш ала. Бу иҗат коллективларының үсеше өчен дә бик мөһим. Фестиваль бит ул Олимпиада кебек, монда кеше факторы зур роль уйный. Барысы да камил була алмый. Киресенчә, без үз хаталарыбызда өйрәнәбез, алар ярдәмендә үсәбез, – диде ул.

Фестиваль Татарстанның район һәм шәһәрләрен генә түгел, Россия төбәкләрен дә колачлый. Быел фестивальдә Мәскәү, Мари Иле, Самара, Пермь, Донецк республикасыннан да катнашучылар булды.

– 22 нче мәртәбә сезнең белән шушы «Созвездие – Йолдызлык» фестивалендә очрашабыз. Бу – чыннан да, зур бәйрәм. Балалар үзләренең талантлары белән безне елдан-ел шатландыра. Монда күпме матурлык, тәрбия, күпме хезмәт куелган. Фестиваль балаларның тормышка карашларын формалаштыруда, кешеләр белән аралашуда зур бер мәктәп булып тора. «Йолдызлык»та катнашу гына да – үзе зур җиңү, – диде Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Хашимова.

Сәхнә белән яшәүчеләр өчен «Йолдызлык» фестивале чын мәгънәсендә иҗади югарылыкка күтәрелүдә бер баскыч булып тора, яңа талантларга ачылырга, үзләрен күрсәтергә мөмкинлекләр тудыра. Сарман районының Әлмәт авылыннан булган 10 яшьлек Азамат Исламов үзен «Конферанс» номинациясендә сыный.

– Әлеге конкурста җиде яшьтән катнаша башладым. Беренче чыгышымда бик дулкынланган идем, берникадәр курку хисе дә бар иде. Сәхнәгә чыккач, ул онытылды һәм мин әйбәт итеп җырладым. «Конферанс» номинациясендә беренче ел катнашам. Финалга үтүемә шатмын, беренче яки икенче урын алырмын дип ышанам, – дип сөйләде Азамат.

Чуашстанның Шыгырдан авылыннан килгән Риана Камалова үз җырлары белән кешеләргә бәйрәм, шатлык, якты хисләр бүләк итәргә хыяллана.

– «Созвездие – Йолдызлык» бәйгесендә катнашу ул – зур горурлык. Мин моңа күптән әзерләндем, зур тырышлык куйдым. Җырларым белән кешеләрне сөендерергә телим. Әлеге зур вакыйганың бер өлеше булуыма чиксез шатмын, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

yold.ru

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 254

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+